Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!


ISSN 0136-7110

Чаян



2

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ФЕВРАЛЬ* 2025 * КАЗАН



Марсель ГАЛИЕВ

ТАБАРЛАР БЕЗНЕҢ ЭЗЛӘРНЕ

Еланнан елау кетмә син,
Еланнан елау кетмә;
Елатыр елларны йолып,
Дөнья тетмәсен тетмә!

Уйлар уйла, бер утырып
Елантау итәгенә.
Халкыңның гомер агачы
Күрмәде ниләр генә?!

Текә язмыш маңгаена –
Күпме әр, күпме яра?!
Янә яшәреп, еланнар
Иске кабыгын сала.

Иске кабыгын сала да
Ысылдап урап ала.
Эчкә елан йотканнарның
Җан күзе салкыная.

Атилла оныкларының
Учагы сүнеп бара.
Үрчи мөгезле еланнар,
Кыйтгалар ятка кала.

Еланнан елау кетмә син,
Еланнан елау кетмә;
Бүген җуйган зурлыгыңны
Үткәннән өмет итмә!

Табарлар безнең эзләрне,
Әйтерләр хәйран калып:
«Үзе үстергән еланнан
Чагылып үлгән халык...»

КИРӘКТЕР ДӨНЬЯ СЕЛКЕТҮ

Уянган шагыйрь. Йокламый.
Дөресрәге йоклый алмый.
Йоклар вакыт түгел шул,
Үткән гомере – аккан су.

Ниһаять төшенгән шуңа –
Афәт килүен каршына.
Шигърият дөньясында ул
Берүзе икән – шашына...

Ачына шагыйрь үткәнгә,
Халкының бәгыре кипкәнгә.
Чакыра барсын керәшкә,
Йөрәккәе әле типкәндә.

Әйтәбез:
– Ходай чакырды!..
Еланнан ишеп чыбыркы,
Синдәй егеттәй – селтәнеп,
Кирәктер бер дөнья селкетү!

Алмаз ХӘМЗИН

Валентин ДУБИНИН



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Хатын-кыз киемендә иң мөһим әйбер – ул киенгән кигән хатын-кыз.

Әгәр сиңа ишәк типкән икән, аңа шуның белән үк җавап бирмә.

Бездә намуслы кешеләр изгеләргә караганда сирәгрәк очрый.

Сөйләмәгән чакта ахмак та акыллы булып күренә.

Башкаларга пычрак аткан кешенең басып торган җире ишелә.

Яла ягудан күпкә көчлерәк корал бар. Бу – дөресен әйтү.

(Зыялылыр мәҗлесендә язып алынды)



ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле «Чаян»! Теләсә нинди котылгысыз хәлдән чыгар юлның кимендә ике чарасы бар, диләр. Беренчесе аңлашыла: кулны кушырып, ни булса шул булыр дип көтәргә. Ничек булса да булыр әле дигән кебек! Ә менә икенчесе турында берни дә әйтә алмыйм. Бәлки, Шомбай ага нәрсә дә булса беләдер?

В. Р-нов

Волжск

– Котылгысыз хәлдән иң дөрес чыгу юлы – ул юлга барып кермәү, – диде аксакалыбыз, укучының хатын укып чыккач.

Нәҗибә САФИНА

Мәсәл вә мәсьәлә

Фикерләре бөртек-бөртек, –
Ташалар ярдан артып.
Чапкан үләннәрен төяп,
Кайта ул арба тартып.

• • •

"Өстә" акылсызлар арткач,
Артты бүген вәзирләр.
Башлык урыныннан киткәч,
Шул урынга әзерләр.

• • •

Күптән ачарга талпынды
Берәү җан җәрәхәтен.
Җитмешкә җиткәч җиткерде
Ул миңа мәхәббәтен.

• • •

Ялгызмын дип, яшь түкмә син,
Өй алдында алмагач
Алмасын җиргә ташлады,
Син дә өзеп алмагач...

• • •

Беркемне дә танымыйча,
Бөек булмакчы иде,
Арбага дегет чиләге
Булып тагылды инде.

• • •

Элек кәнәфи иде,
Хәзер инде – кресло.
Хезмәт итә аларның
Барысы да кресқә.

• • •

Гомер лотерея түгел,
Отып алырга.
Салым акчасы да түгел,
Тотып калырга.

• • •

Җир маен ашап,
Маемлаган өчен
Җирдә дәва булмас.
Артык азынганнар өчен
Җирдә дәвам булмас.

Вячеслав ШИЛОВ



СЕЗ БЕЛӘСЕЗМЕ...

- Ирләр алар тавык кебек: өйдән егерме адымда беркемнеке дә түгел.
- Кызларга ошар өчен акыллы, чибәр, бай йә ата мәче булырга кирәк.
- Ярты ил бер гаепсезгә интернетта утыра.
- «Максатлы реклама» – гадәттә, кеше ашап утырганда телевидениедән бара торган эч китүдән, эч катудан һәм простатиттан чаралarга реклама.
- Вакыт – иң яхшы дәва. Һәрхәлдә, гади һәм арзан.

Виталий ПОДВИЦКИЙ



Ясалма интел-лект

– Күпме ялган акча таралды хәзер – базарда сдача алырга да куркыныч! – дип уфтанып куйды Комсызбаев.

– Әйтмә дә инде, – дип җөпләп куйды Күпергәнев. Аның бит әле сыйфаты да шундый түбән, ул кәгазь кисәкләренә карт әби-бабайлар гына каба.

– Шулай инде, шулай. Ялган акчаның сыйфатын бик нык, төптән яхшыртырга кирәк. Яшьләр һәм байларны да өтәрлек булсын, алары җәл түгел.

– Әйе. Әле суперпринтер алуыбыз һәм компьютерга ясалма интеллект куюыбыз да бик шәп булды.

– Аның белән эшләр җайга салыныр дип уйлыйм! – Комсызбаев кулларын уып куйды һәм кесәсеннән биш меңлек тартып чыгарды. Ул аны монитор каршына китереп кыштырдатып алды, кәгазь кабул итүче ярыкка кертеп җибәрде һәм микрофонга әмер бирде: "Йәле, энекәш, шуның күчермәсен ясап бир әле!"

Компьютер гөжләп алды, экраны һәм барча индикаторлары белән "күз кыскалады" һәм чын акчаны эшмәкәргә кайтарып бирде, ә икенче ярыктан күчермәсен "төкереп" чыгарды.

– Кара син аны, ә! – дип сокланды Комсызбаев. – Чыныннан аерып та булмый бит. Бөтен сурәтләре үз урынында бит! Ләкин, ничек дип әйтергә... энекәш, безгә зур акча кирәк шул.

Җайланма тагын гөжли башлады һәм тиздән ярты гәзит бите зурлыгындагы биш меңлек чыгарып бирде.

– Тфү, мәнә сиңа "зур акча"! Бөтенләй онытып җибәргәнбез бит, ул бит барысын да сүзгә-сүз кабул итә. Йә, әйдә әле, йөз данә төгәл күчермә чыгарып бир!

Бу юлы аппараттан җавап яңгырады: "Булдырабыз аны!" Ун минуттан шатлыктан исергән дуслар пачка-пачка буяу исе аңкытып торган кәгазь акчаларны учларында иркәлиләр иде.

– Менә бу байлык, ичмасам! Тагын берничә тапкыр чыгарсак, җылы диңгез буйларына юл тотарга була.

– Әйе, булыр сиңа диңгез буе... – Комсызбаевның чырае караңгыланды. Ә такта ятаклы баракка теләмисеңме?.. Пачкаларда номерлар бер үк шул. Күреп алу белән йомшак урыныңнан әләктереп алырлар.

– Син хаклы бит, анасын сатыйм. Хәзер без аны...

Күпергәнев принтерга тагын ике өем кәгазь куйды һәм микрофонга чын акчадагы серия номерын укыды.

– Менә нәрсә, интеллект энекәш. Безгә мең копия бастырып чыгар әле. Тик номерлары, сигез-биш-өч-өч-ике-нольдән башлап, бер-бер артлы үсеп барсын.

Эшләүче принтер тавышын тыңлый-тыңлый алар өстәл янына утырдылар һәм ашыкмыйча кофе эчә башладылар.

– Кара син аны! Бетерде инде әллә? – дип шатланды Комсызбаев, сәгатенә карап алгач. – Тиз тотты бу, маладис!

– Тулысынча тәмамладым, – дип җавап бирде ясалма интеллект. – Тиешле мәгълүматны да тапшырдым...

– Нинди мәгълүмат тагын?!

– Автоматик рәвештә дөнья тәҗрибәсен анализлау нигезендә, акча чыгару рәсми акт булып санала. Сезнең шәхси эмиссиягез турындагы мәгълүмат, купюраларның номерлары һәм шулай ук эмиссионерлар турындагы тулы мәгълүмат Россия банкына, Салым хезмәте һәм Эчке эшләр министрлыгына җибәрелде. Сезне артык мәшәкатьтән азат иттек. Рәхмәт сүзе кирәкми.

Комсызбаевның соңгы йотым кофесы тамагында төелеп калды. Ә Күпергәнев почмакта аунап яткан юл сумкасын алды һәм ашыга-ашыга кулына беренче туры килгән әйберләрне тутыра башлады:

– Бәлки, өлгерербез әле... Тизрәк ычкынырга кирәк!

Ишекне япканда ул борылып карады һәм башын селкеде:

– Их, интеллект, интеллект!.. Электрон әләкче! Кемгә генә охшап шундый булгансың икән син?!

Евгений ОБУХОВ

Валентин ДРУЖИНИН




Михаил ЛАРИЧЕВ




Вячеслав ШИЛОВ



Максим СМАГИН





ЙӨРЕМСӘК МӘЗӘК

• • •

Бер чибәркәй йөртүчесез таксига утыра да гаҗәпкә кала:

– Нишләп соң бу автомобильнең йөртүчесе юк!

Ә машина моңа җавап бирә:

– Беләсегез килсә, мин бизнес өчен ясалма интеллект, ә такси – болай гына, өстәмә рәвештә акча эшләп алу өчен.

• • •

Хатыны – иренә:

– Син тагын диванда ятасың...

– Шуңа күрә син мине һәр кирәк чакта таба аласың.

• • •

– Доктор, интернет ярдәмендә кәефемнең китү сәбәпләрен ачыкладым. Әмма башка фикерләр ишетеп булмас микән, дип, сезнең янга да кереп чыгарга уйладым.

• • •

Әгәр рекламага ышансаң, банк мохитендә барысыннан да бигрәк актёрлар, спортчылар һәм шоу-бизнес йолдызлары ныграк акыл йөртә.

• • •

Сантехник белән бәхәсләшкән кешене күргәнем юк. Ә менә табиб фикере белән килешмәгән кешеләрне күбрәк беләм. Әллә унитаз кеше организмыннан да катлаулырак, әллә табибка караганда сантехниктан ныграк куркалармы...

• • •

– Әти, син әле үсәчәксеңме?

– Юк инде, улым.

– Ә алай булгач, нигә ашыйсың?

• • •

– Бузова концертына билет кирәкме?

– Күпме тора соң ул?

– Бушка бирәм!

– Нигәдер кыйбат.

• • •

– Әгәр лотереяга 100 миллион отсам, минем янәшәмдә ярлылар булмаячак, вәгъдә бирәм!

– Чөнки яшәргә байлар өчен ябык бистәгә күчәчәксең?

• • •

Пенсия фондындагы каты сугыштан соң, скандинавия таякларына таянып керү катгый тыела.

Абау!

ШАКШЫ «ЧИСТА СУЛАР»

Биектау районындагы "Чистые воды" ("Чиста сулар") компаниясе пычрак суларны җыю һәм чистарту белән шөгыльләнгән. Дөрес, бу эш кәгазьдә генә башкарылган, ә чынлыкта исә тирә-юнь мохитне саклау белән баш катырмыйча, җыелган суны "Малиновый овраг" бакча ширкәте янындагы Каменка елгасына түгеп барганнар. Белгечләр бу урында зыянлы матдәләр күләменең рөхсәт ителгәннән берничә тапкыр артыграк булуын ачыклаганнар. Тиешле эшне башкармыйча, фирманың күпме акчаны янга калдыруы билгесез, әмма моның өчен салынган зур гына штраф суммасы – 8 миллион сум булып чыккан.

КУЛ ҖИТМӘС ОЯ

Соңгы биш ел эчендә Казанда фатирларның уртача бәясе 5 миллион сумга арткан. Әгәр 2019 елда ул 2,5 миллион сум тәшкил иткән булса, 2024 елда 7,4 миллионга җиткән. Һәм бу әле чик түгел. Әгәр дә бәяләр шундый тизлек белән арта барса, ел ахырына "гаилә оясы" өчен 10 миллион сум түләргә туры килмәгәе.

АТКА БАРЫП ҖИТМӘГӘН "СОЛЫ"

Казан ипподромындагы урлашулар буенча җинаять эшен тикшерү тәмам. Вакыйганың асылы бик гади. Бюджеттан даими рәвештә ат чабышлары уздыру, нәселле атлар сатып алу, һәм башка ихтыяҗлар өчен акча бирелеп барган. Әмма бу суммалар тиешле урынга китмәгән – аларның ярыйсы гына өлеше ипподром директоры һәм аның урынбасарының кесәләрендә утырып калган. Тикшерүчеләр фикеренчә, 24 миллионы урланган.

ЯҢАЧА ЙӨРҮ

Чаллыда яшәүчеләр мәскәүлеләр тарафыннан эшләнгән яңа шәһәр транспорты маршрутлары схемасыннан ризасызлык белдергәннәр. Хәзер, күченеп утыру аркасында, күбрәк вакыт һәм акча китә башлады, дип саный алар. Моңа җавап итеп шәһәр хакимияте уңай үзгәрешләр өчен җитәкчелеккә рәхмәт укучы кешеләрнең видеосурәтләрен күрсәтә. Шәһәр транспорты 1 гыйнвардан яңача йөри башлаган. Транспорт бәясе дә 40 сумга кадәр күтәрелгән.





СӘХНӘ ТОРМЫШЫ – УЕН



Сергей КОКАРЕВ



Игорь КИЙКО



Александр АЛЁШИН

Михаил МИХАЙЛОВ

КОМПАНИЯ СӘЯСӘТЕ

– Каршы алыгыз! Сезнең чакыруыгыз буенча ашыгыч монтаж ясау өчен килдем. Безнең клиент һәрвакыт беренчелектә – бу компания сәясәте.

– Без әзер, монтаж ясый башлыйкмы?

– Договорда күрсәтелгәнчә, мин башта сездә техника куркынычсызлыгы буенча инструктаж үтәргә һәм махсус эш киеме, каска алырга тиеш. Шулай ук яшәү өчен урын бирергә, ашау-эчү, транспорт...

– Рәхим итегез! Монтажлый башларга мөмкинме?

– Әлегә юк! Баш офис килүем турында язма отчёт таләп итә, договор пунктларын үтәүне сорый, аннан соң мин баш офиска шалтыратырга, отчёт килүенә төгәл җавап алуга ышангач кына...

– Ну, шуннан ниһаять монтажга керешергә мөмкиндер бит...

– Супервизорсыз эш башларга ярамый, ә минем инде командировкада булу вакытым бетте... Озайтырга кирәк! Беренче өч көнне безнең компания тик яту итеп рәсмиләштерә! Гафу итегез, әмма бу безнең компания гаебе түгел! Бу очракта, договор буенча, икеләтә түләү каралган...

– Ярар, риза, әйдәгез хәзер үк озайтырбыз һәм монтажлый башлыйк!

– Башта баш офиска озайту турында белешмә бирик, килешү карарын алыйк һәм шуннан соң гына шунда түләү турында гарантия хатын җибәрик... Договорда шулай язылган...

– Сез монда инде ике атна, бәлки, җиһазны монтажлый башларбыз?

– Эш миндә түгел, сезнең монда ниндидер аңлашылмаучылык, баш офиска шалтыратыйм әле...

Менә хәбәр бирделәр, эш башланмыйча тору сәбәпле, мондагысын ташлап, икенче җирдәге объектка тиз арада күчәргә кушалар... Яхшылап әзерләнеп торыгыз һәм чакырыгыз, һичшиксез килермен! Компания сәясәте мине моңа мәҗбүр итә...

Машина-ТАМАША



ЮЛ ШАЯРТУЛАРЫ

– Нигә син машина алмыйсың? Синең акчаң күп бит!


– Менә шуңа күрә ачам күп тә инде минем!

• • •

Яңа машина сезнең акчагыз күпме булганның күрсәткече була алмый, ләкин сезнең күпме тиеш икәнегезнең күрсәткече була ала.

• • •

Машина зур булса, ул барган юл төп юл булып санала.





ЙӨРҮ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ

Мамадыш тракты көн саен Питрәч районыннан һәм тирә-юньдә төзелгән күпсанлы яңа торак комплексларыннан килгән машиналар ташкынын кабул итә. "Бөке"сез вакытларны хәтта җирле кешеләр дә хәтерли алмый. Аны төзегәндә "запас юл" – Вознесение трактына зур өметләр багланган иде. Ләкин көтмәгәндә аны түләүле итәргә булдылар. Вәгъдә ителгән икенче юнәлеш гап-гади "коммерция проекты" булып чыкты. Ташкын беркая да китмәде, әмма автомобильләр түгел, ә шикаятьләр ташкыны. "Запас юл"дан узу бәясе иң "кайнар" вакытта җиңел автомобильләрдән 150 сум тәшкил итә, ә көн саен анда-монда йөрүче җирле халык тир түгеп тапкан акчасын асфальт өчен калдырып китәргә теләми. Тракт эшли башлауның беренче көннәреннән үк ачыкланды: машина йөртүчеләр комфорт белән йөрү өчен түләргә атлыгып тормыйлар. Мамадыш юлындагы хәлдән тайдыргыч "бөке"ләр беркая да китмәде. Шулай да тора-бара кешеләр шәһәр эчендәге түләүле юлларга ияләнерләр дә, һәм машиналар Вознесение трактына да агыла башлар дип өметләнә хакимият. Ләкин бу озак дәвам итәр микән? "Запас юл" тирәсендә торак комплекс салырга җыеналар, димәк, "бөке"ләр – түләүлеләре дә, түләүсезләре дә барыбер булачак. Бу очракка нинди дә булса чара кабул ителер микән?

• • •

Машина йөртүченең осталыгын арттан барган инспектор машинасы кебек бернәрсә дә арттыра алмый.

• • •

Автомобиль – ул гади хәрәкәтләнү чарасы, ә бензин – кыйммәтле зиннәт.



КАЙБЕР ШӘХЕСЛӘРДӘН АКЫЛЛЫ ФИКЕРЛӘР

Сүзләр ашыга, ярар – шуннан ни булган!
Син беркайчан курыкма соңлаудан.
Сүзләр күп алар, ләкин булдыра алсаң
Кайчан әйтергә чынлап уйлаудан –
Әйт. Кире кайтма шушы уеңнан!

Владимир ВЫСОЦКИЙ, рус шагыйре.

Гомуми акыл – рух тудыру өчен, җирәнгеч затны яратырга өйрәнү кирәк – ягъни үзеңне, һәм моңа омтылучы кеше һичничек тә тормышның бер генә тармагыннан читләшергә тиеш түгел.

Мохан Дас Ганди, һинд сәясәтчесе.

Утырып үлем көткәнгә караганда, эштә килеш үлүең яхшырактыр.

Николай ГАРИН, рус язучысы.

Бердәнбер матурлыкны беләм – ул сәламәтлек.

Генрих ГЕЙНЕ, немец шагыйре.

– Эреми торган боз кебек, хроник бәхет тә була алмый.
– Сүз үлмәгән икән, димәк анда әле гамәл дә яши.
– Әйтә алу көче һәм гамәл кылу – икесе бер нәрсә.

Александр ГЕРЦЕН, философ.

Меңнән берәү аңласа да мине,
Шул да бәхет шигъри күңелгә.
Чыкма, йөрәк, шигърияттән читкә
Әв(е)релгәнче янып күмергә!

ХӘМИДИ, татар шагыйре.

– Сугыш, ауда чактагы һәм сайлаулардан соңындагы вакытлардан да ныграк алдау булганы юк.
– Сәясәттә катнашмау – кешене аның нәтиҗәләре коткармый.
– Сыра эчүдән ялкаулык, аңгыралык, көчсезлек барлыкка килә.
– Революцияне романтиклар уйлап чыгара, фанатиклар башкара, ә рәхәтен әтрәк-әләмнәр файдалана.
– Мин, Аллага шөкер, генерал түгел, димәк, бу әфәнделәр кебек ишәк тә була алмыйм.

Отто фон БИСМАРК, немец сәясәтчесе.

Алмаз ХӘМЗИН әзерләде.

Рөстәм ЗАРИПОВ

МИН УЛ ЗАТКА ЙӨЗ ЕЛ ГОМЕР ТЕЛИМ...

Гаилә елы дип тамамланган елны, яшь әни бәби табу йортында чакта, аның ире – яшь әтине кемгәдер урыны кирәк санаганга, эшеннән бушатып, яшь гаиләне көтмәгәндә авыр хәлдә калдыручы шәхескә багышлап язылды...

Сиңа күршең йөз ел гомер теләдеме?
Ә күршең бит сине каргаган...

Алишер НАВОИ

Мин ул затка йөз ел гомер телим,
Юк, йөз ел аз, мең ел яшәсен.
Барлык талаганын, хаптыр-хоптыр,
Рәхәтләнеп мең ел ашасын...

Балалары мең ел гомер сөрсен,
Оныклары мең ел күшәсен,
Әйдә, сыптырсыннар бер утыруда
Дүрт аяклы маллар түшкәсен...

Андый "уңышлыларның" артыгы,
Ул бит мәзлүмнәрнең актыгы.
...Еллар узган саен өскә чыга
Тукай дәреслеге, хаклыгы.

Мин ул затка йөз ел гомер телим,
Юк, йөз ел аз, мең ел яшәсен,
Күбенгәнче эчсен мескеннәрнең
Күз яшьләре тулы касәсен...

Абау!

Коткаручылар чакырдыгызмы?

МӨМКИН ТҮГЕЛ

Камчаткада яшәүче берәү мөмкин булмаганны эшләгән – ул телефон мошенникларын акчага алдаган. Билгесез кеше аның белән элемтәгә кергән һәм 200 мең сумга полиция машинасына ут төртергә тәкъдим иткән. Ул ризалашкан, ләкин аванс буларак 50 мең сум сораган. Акча алганнан соң аны эчеп бетергән, аннары тагын 20 мең сораган. "Яндыручы" шулай ук бу сумманы иң якын эчемлек кибетендә калдырган, һәм мошенникларның шалтыратуларына җавап бирүдән туктаган.

ПАСПОРТ

Федераль эзләнүчеләр исемлегендәге кеше очраклы рәвештә Санкт-Петербург полициясенең кулына эләккән. Ул югалган паспортын торгызу үтенече белән полиция бүлегенә мөрәҗәгать иткән. Хезмәткәрләр гражданнар базасын тикшергәннәр, һәм Новосибирск өлкәсенең Хокук саклау органнары аны озак эзләүләрен ачыклаганнар. Бәхетсез качакны, детальләре билгеле булганчы, төрмәгә япканнар. Дөрес, бер уңай ягы шул – аның паспорты тергезеләчәк.

ТӘВӘККӘЛ ТРАДИЦИЯ

Воронеж фотографы Владимир Малдер Рәсәйнең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының төбәк бүлегенең мактаулы таныклыгына лаек. Ләкин андагы сүзләр гадәти булмаган булып чыккан – "физика законнарын һәм гади акылны җиңәргә тырышу өчен". Эш шунда ки – ул салкыннар килү белән елга буйлап тимераякта бозның ныклыгын сынап карый. Менә шундый куркыныч традиция. Вакыты-вакыты белән "тимераякта шуучыны" коткарырга туры килә. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Воронеж резидентының, гадәти булмаган сертификат тапшырып, шикле казанышларын билгеләп үткән.

СИН МИНЕ АҢЛАМЫЙМ

Нижний Новгород университеты ректоры мигрант студентларны укырга кертеп, бюджеттан 1 миллион үзләштергән. Алар дәресләргә йөрмәгән, рус телен аңламаган, нинди фән барын, Менделеевның кем икәнен, Россия башкаласының шәһәр исемен, аннан гадәти сорауларга да җавап бирә алмаганнар. Шуңа да карамастан, курстан курска уңышлы күчеп барганнар һәм диплом алганнар. "Эшлекле" ректорны кабинетыннан ук кулга алганнар.









Никифор ТУКМАЧЁВ

КИҢӘШ

Дару эчтем учлап-учлап,
Рекламаларны тыңлап.
Саулыгым ярыйсы иде,
Эчтем алдагын уйлап.

Дару эчтем йөрәктән дә,
Үпкәдән һәм бавырдан.
Юкка түгел дару исе
Килә, диләр янымнан.

Пенсия акчасы җитми,
Дарулар ала-ала.
Сәламәтлек күптән бетте,
Реклама һаман бара.

Минем көннәргә калырсың,
Ала күрмә дарулар.
Рекламаларны тыңласаң,
Ыштаның салдырырлар!!!

Беләм юкса алдашалар,
Ник укыйм, карыймындыр...
Инде үзем дә дефицит –
Даруга ярыймындыр.

Ренат ГАФФАР

ДАРУ ИСЕ

Гадәттә, физик халкын лирик, диләр. Алай гына түгел икән ул. Медикларны да авыз тутырып әйтергә була каләм кыштырдата торган лирик дип. Әнә бит, урысның, яһүднең күпме табибы скальпель урынына каләм тибрәтеп тамак туйдыра, җан асрый, көн күрә.

Без – татарлар арасында да аның ише гавам. Шәриф Хөсәеневнең мәңге үлмәс пьесаларын кайсыгыз белми, әйтегез? Язучы Нәкыйп Каштан да – табиб кеше. Терапевт буларак, ачуым бер килмәгәе, чирек гасырдан артык вакыт буена кеше шәһрәтен алган Ринат Мәннан исә иң-иң сирәк һөнәр иясе иде – пародия остасы рәвешендә мәдәният тарихында мәңгелеккә калды. Ташка баскан хәтлесен укысаң, укыганнарын тыңласаң, һәммә шигыреннән дару исе килеп тора!



Валентин ДУБИНИН



Михаил ЛАРИЧЕВ



ҮТКЕН ПЕРСИДӘТЕЛ

Яхшы кешеләргә закон кирәк түгел, ә начарлары булганнарын да үтәми. Яшел Үзәндәге йортларның берсендә яшәүчеләр үзләренең торак ияләре ширкәтенең рәисен "асраганнарына" төшенгәннәр. Ханым ел буе фатир ияләренең капиталь ремонт өчен җыйган акчаларын үзләштереп барган. Капиталь ремонт – тиз эшләнә торган нәрсә түгел, шуңа күрә бу хәлне тиз генә сизмәгәннәр дә. Дөрес, рәис бик зур сумма әләктерә алмаган, тик шулай да фатир ияләренең кесәләреннән 17 мең сум тартып чыгарырга өлгергән. Рәис ханым үзен гаепле итеп танымаган, әмма суд башка фикердә торган һәм аңа колониядә ике ел ярым билгеләгән. Өстәвенә, элеккеге рәискә өч ел буе ул өлкәдә эшләү тыелган. Алайса, кем белә бит...

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Кагыйдә

Чит ил кешеләре белән интернет аша танышканыгыз бармы? Бигрәк тә кызык алар белән аралашу.

Берничә ел элек Европада яшәүче һинд егете белән танышкан идем. Минем Рәсәйдән икәнемне белгәч, беренче соравы шул булды: "Син бүген нәрсә ашадың?" Мин әйтәм: "Ник алай сорыйсың? Кеше туклана торган ризыкны ашадым", – димен. "Әйт инде, миңа кызык бит, Рәсәй кешеләре нәрсәләр ашый икән", – ди. Әйттем. Соңыннан көн саен шул сорау бирелде: иртән, көндезен, кичен нәрсә ашадың, дип.

Андый "нәрсә ашадың" дип сораучылар күп булды. Миңа бик сәер тоелды андый хәл. Ә аларда ул гадәт икән. Соңыннан, башкалар белән аралашканда исем китми башлады.

Тагын безнең халык өчен сәер бер нәрсә бар. Аларда "Как вы поживаете?" дигән сорауга, мондый җавап: "спасибо, хорошо, а вы?" Ә бездә ничек? Сөенечең булса, уртаклашасың, барысын да сөйлисең. Беркатлы кешеләр без.

Шуңа күрә бу яңа дустым, хәлләрең ничек дип сорагач, мин сөйли башладым. Бу юлы инде аның исе киткәндер. Алар өчен гади нәрсә түгел бит...

Әлеге дустым белән шактый еллар аралашабыз. Ул күнегеп бетте безнең гадәткә, ә мин аларныкына. Хәзер хәлләрең ничек дип соравыма, ул барлык тормышын сөйли башлый. "Синең белән аралашырга рәхәт, психологларга акча түздырып йөрисе юк. Борчыган нәрсәне дә сөйләргә була, сөенечне дә. Сезнең илдә психологлар юктыр, мөгаен. Берберегез белән сөйләшкәч, күңел тынычланадыр. Бездә андый нәрсәләр юк шул, кызганыч", – ди.

Чит ил кешеләренә бездән күп нәрсәгә өйрәнәсе бар икән. Ашау кайгысы гына түгел, кеше белән аралаша белү дә бик мөһим.



Александр ШУЛЬПИНОВ

Валентин ДУБИНИН

Виктор БОГОРАД

Вячеслав ШИЛОВ

Телефон шантажы, дисезме?

Әйе, ай саен телефонга түләмәгән өчен, өзеп куябыз, дип куркыталар...

Аркадий ЦОГЛИН

ГОРУР КЕШЕ

Мин күршем Валера белән инде биш ел буе таныш. Ул бик гади кеше, мәрхәмәтле һәм безнең аның белән бернинди дә аңлашылмаучылык килеп чыкканы булмады. Менә соңгы тапкыр бер көтелмәгән хәлдән соң ул үзенең чын йөзен күрсәтте...

Эш менә болай булды. Бер ай элек бик салкын кыш көнне, мин дуслар белән бераз салганнан соң, чак кына өйгә кайтып җитә алмаганмын. Көрткә утырганмын да йоклап киткәнмен. Фатирда аңга килдем. Хатыным барысын да аңлатты – мине Валера алып кайткан икән. Очраклы гына кар өстендә ятканымны күреп, иң өстенә күтәреп китергән. Шулай итеп, ул мине үлемнән коткарган.

Әлбәттә, әлеге мәрхәмәтлелеге өчен мин Валерага бурычлы – шуңа күрә аны кунакка чакырдым. Шәп итеп табын әзерләдем – хатын каз ите кыздырды, чын кызыл икра таптым, яхшы шәраб куйдым, торт та өстәл уртасына менеп кунды. Инде мине коткарган кунакны көтәбез. Вакыт үтә тора, ә ул һаман юк та юк. Шалтыратам, исенә төшереп. Валера гафу үтенә һәм килә алмавын әйтә – янәмәсе, эше тыгыз, кинәт авырып киткән хезмәттәшен алыштырган. Мин идәнгә утыра яздым! Шундый табынны кичектермәс эшкә алмашкан?!

Моңа бигүк ышанып та бетмәдем, ягъни хәйләсен аңламадым. Нишләргә инде хәзер моның белән дип уйладым. Аны бит ничек тә булса бәхилләтергә кирәк коткарганы өчен. Миндәй кешеләрне көн саен өйләренә ташый башласаң?.. Очраштык та аңа үземнең моторлы көймәмне тәкъдим иттем. Ул бигүк төзек тә түгел инде, ләкин әле хуҗасына байтак вакыт хезмәт итәргә мөмкин. Берәү булса шатланып алыр иде, ә бу, җитеп бетмәгән нәрсә, бүләктән баш тартты. Яр читеннән кармак белән генә балык тотарга яратам, ди.

Шунда аңладым: Валера горур кеше икән. Мөгаен, махсус бүләк көтәдер – кыйбатлы. Хатын белән киңәшеп алдым да төрек дублёнкасы бүләк итәргә карар кылдым. Аны хатынымның әтисе өч кенә ел киеп йөргән – әйбәт килеш. Валера бүләкне күрү белән кызарып куйды, әллә шатлыктан, әллә башкадан... Алмыйм, рәхмәт, үземнең курткам тәнемә җайлы, ди. Ну, горур булса да булыр икән?!

Ачуым чыкты, мин бит моңа хәзер гомерем буе бурычлы булып йөриячәкмен? Төннәрен йокым качты, нишләргә соң бу горур бәндә белән? Хатын: “Бу бик хәйләкәр кешегә охшаган, зур сумма таләп итмәкче буладыр”, – ди. Бәлки, шулайдыр дип уйладым. Валера гади булып кылана гынадыр, ә уенда башка нәрсәдер. Коткы чыгармакчыдыр...

Валераны төп башына утыртырга кирәк дигән фикергә килдем. Туктале, мәйтәм, аның өй ишеге төбенә үземнең смартфонымны ташлап калдырыйм һәм күзәтим, нәрсә эшләр икән: алырмы-юкмы? Мин тогәл фикердә – ала һәм эндәшми. Ә сез нәрсә уйладыгыз инде – шул минутта ук Валера телефонымны кертеп бирде, горур шайтан. Фотоларыннан телефонның минеке икәнен белгән. Менә шуннан соң инде, ниһаять, моның чын йөзен ачыкладым: чыннан да, ул мине чишендерергә маташа. Утырам һәм юрыйм, ни уйлаган бу хәйләкәр? Ә ул һаман минем яннан үтеп-китеп йөри, ягымлы исәнләшә, һични уйламассың, җәзасын әзерли. Бу кыланмышы бит инде бернинди кысаларга сыймый! Бөтенләй борынын чөйде Валера! Бер генә борчуым калды: ничек итеп бу горур җанны акылга утырту. Бәлки, фатирына ут төртеп яндырыргадыр?

Альберт ГАДЕЛШИН

РАДИОНЫҢ АЛТЫН ФОНДЫ

Байлар Сабасы районында йөрибез.

Ун концерттан, ун көннән соң алҗыттыра. Гали ага Җәмлиханов та "суточные" беткәч кәефсезләнә башлый иде.

Бераз кызмача да бугай, Гали абый тиккә үзенең "бөеклегенә" сокланып сөйләшә башламас иде:

– Менә, исән булсам, бу дөньядан киткәч тә, мине радиокомитет искә алачак. Мин татар музыка сәнгатенең алтын фондына кергән кеше, – ди.

Аның белән бәхәсләшер кеше булмагач, бу миңа карап-карап торды да:

– Менә син, Альберт Гаделша, кем? Гади бер фокусник – обманщик. Синең кебек фокусниклар базар тулы җимеш саталар. Үлсәң, искә алучы да булмас, ди.

Мин дә бирешергә теләмим. Күрәм, коллегалар хәзер мәзәк буласын көтәләр.

Исем китмичә генә:

– Һәй, Гали абый, кем соң инде балачага гармушкасында уйнап, татар сәнгатенең алтын фондына керә алсын. Андый балалар гармушкасында минем Рәйхәт исемле энекәш тә мич башында кычкыртып утыра, – дип, кул селтәгән булдым.

Чираттагы авылга барып җитеп, фатирларга урнашып, кичен концертка әзерләнәбез. Сизәм, Гали абый биюче Петр Загудаевка миңа каршы ниндидер "этлек" эшләргә куша. Аларны читләтеп кенә күзәтәм, сизенәм, минем фокус күрсәтә торган реквизитлар белән нәрсәдер эшләргә җыеналар.

"Ул-бу" булмасын дип, берничә трюк күрсәтә торган кәртләр колодкасын сәхнәгә чыга торган "тылсымлы" өстәлдән алып кесәмә салдым да, ә серле кәртләр урынына гади колода кәртләре куйдым.

Мин читкә борылган арада, тегеләр, өстәлдәге серле дип уйлаган кәртләр колодасын алыштырдылар.

Чыгыш ясарга миңа чират җитте. Иллюзия реквизитлары куелган өстәлне үзем алып чыгып куеп, баянчылар Рәфкәт Лотфуллин белән Ганс Сәйфуллин "минем музыканы" уйный башладылар.

Як-ягыма, сәхнә артына карасам, бөтен бригада артистлары минем чыгышымны кызыксынып карыйлар.

Хәзер кәртләр белән күрсәтеләчәк фокуслар "провалится" дип көтәләр. Мин инде алар куйган кәртләр урынына үземнең серле кәртләрне алыштырып куярга өлгергән идем.

Тамашачыларга мөрәҗәгать итәм: хөрмәтле тамашачылар, менә шушы кәртләр белән күрсәтеләчәк фокуслар Татарстанның атказанган артисты, данлыклы музыкант-гармунчы һәм аның язмалары татар сәнгатенең алтын фондына кергән Гали ага Җәмлихановка багышлана, дип, кәртләр белән фокуслар күрсәтә башладым...


"Хохма" көткән баянчыларга, әйдә, уйнагыз! – дип боерык бирдем.

Кәртләр белән булган бөтен трюкларны уңышлы күрсәтеп, чыгышымны тәмамладым.

Сәхнә артына чыккач, Гали абый елмаеп кулдан кысып: "Молодец, поздравляю, профессионал икәнсең. Сине дә алтын фондка кертербез... бәлкем", дип әче итеп көлде.



Эрнст ГЕЛЬМС, 1976 ел.



Иван ХАНТЕМИРОВ, 1982 ел.



• • •

Берәүләр Җирне түгәрәк дип уйлыйлар. Икенчеләр аның тигез булуына ышана. Бары тик травмпунктта гына дөресен беләләр: Җир тайгак.

• • •

– Нишләп син күңелсез? Нәрсә булды?

– Минем егетем миңа хыянәт итә.

– Әхмәтме, Равилме?

– Рафаэль.

• • •

Ике борча пеләш баш өстендә чабыша, берсе көрсенеп кенә икенчесенә болай ди:

– Хәтереңдәме, заманында камышлы уйный идек монда?..

• • •

Хәзерге вакытта табибларның "авыруның хәлен җиңеләйттек" дип сөйләгәннәре ничектер ике мәгънәдә яңгыраган кебек тоела.

• • •

– "Укырга, укырга һәм тагын бер кат укырга!" нәрсәне аңлата?

– Бер имтихан һәм икене яңадан бирү!

• • •

Хатын-кыз бала тудырып кына ир-атның 37,2 температурасыннан ничек газапланганын чамалый ала.

• • •

– Бүген автобуста кондуктор миңа билет алмаган кешегә караган кебек карады.

– Ә син түләгән идеңме соң?

– Юк. Ләкин мин аңа билет алган кебек карадым.

• • •

– Яратуымны сиңа сүзләр белән аңлата алмыйм...

– Акчалата белдер.

• • •

Ике дус сөйләшә:

– Мин үземнең хатынымны "куяным", "балыгым", "кошкаем" дип йөртәм...

– Ә ул нишли?

– Колагын җәя, күзләрен акайта, томшыгын шакылдата!





Александр АЛЁШИН

Михаил ЛАРИЧЕВ






УЙДЫРМАДАГЫ АВТОБУСЛАР

Хөрмәтле редакция! Тормышта урын табуы җиңелрәк, диләр, хәрәкәт тыгыз вакытта автобуста урын табуга караганда. Ә менә безгә Коры Елга (Сухая река) җирлегендә яшәүчеләргә автобусның үзен табуы да кыен бит әле. "Чаян" инде җәмәгать транспорты белән безнең бистәдә кыенлыклар барлыгын бер мәртәбә язган иде, шуннан соң бу мәсьәлә тагын да ныграк кыенлашты. Берләнбер 37А маршрутында ике генә автобус калып, 40 минут интервал белән йөри башлады. Бу теоретик яктан шулай, ә чынлыкта берсе генә эшли. Анысы да әле бик сирәк күренә, транспорт буларак чутланмый да бугай, алда ни булачагы билгесез – күрәзәчеләр дә әйтә алмый. Шуңа күрә тукталышка чыгабыз да бәхет көткән кебек көтәбез. Балаларга мәктәпкә барып җитү өчен 15 минут вакыт җитә, ә автобус көтсәң ике сәгатьләп сарыф ителер иде, бер якка һәм шуның кадәр – кирегә. Бу маршрут безгә бик кирәк, ансыз без "олы җирдән" аерылган кебек тоябыз үзебезне. Хакимият гаепне ташучыга тага, ә тегесе, үз чиратында, йөртүчеләрнең юклыгына сылтый, янәмәсе, алар чын, төзек машиналар көтә, уйдырмалыларны түгел.

Коры Елга бистәсендә яшәүчеләр.

КАЗАН


ҖИМЕРГЕЧ ПРОЕКТ


Кадерле "Чаян". Монастырь елгасы кушылдыгы аркылы салынган күпер бөтен тирә-юнебезнең астын өскә әйләндергән кебек булды. Ул безнең йортлардан бик ерак түгел, берничә метрда гына. Андагы мәшәкатьләр субай суга башлагач барлыкка килде – йорт стеналарында ярыклар сызылып китте, плиткалар купты. Урамнардагы лампа баганалары кыйшайды, канализация торбалары, түзмичә, тишелде. Баганаларны турайтып куйдылар куюын, әмма канализация торбаларын соңгы өч айда ун тапкыр ремонтладылар сыман. Шул шартлаган торбалар тирәсендә – җимереклек: чокыр-чакыр, ишегалларында тәртипсезлек.

Тирә-юньне уңайлы яшәү хәленә китерү комитеты мондый ташландыкка дучар булуга күпернең гаебе юк дигән фикердә. Ә кем җаваплы икәне билгесез. Безгә шунысы мәгълүм: өй түшәме җимерелеп берәрсен басса, гаеплене шундук табачаклар.

Нижнекамск урамында яшәүчеләр.

Борисково бистәсе,
КАЗАН









Хәниф Хөснуллин 1935 елның 7 февралендә Татарстанның Түбән Кама районы Шаңгәлче авылында туа. Мәктәптә укыганда ук кулына каләм ала, иҗат эшен Алабуга китапханә техникумында, Казан дәүләт педагогика институтында укыганда да туктатмый. Чаллы районы Биклән авылы мәктәбендә укытырга китәсен белгәч, аңа районкүләм әдәби түгәрәк эшен җанландыру бурычы куела. Шулай итеп, 1963 елда атаклы «Ләйсән» әдәби-иҗат түгәрәге барлыкка килә.

Авыл мәктәбендә ул тарих һәм татар әдәбияты укыта, мәктәп директоры булып эшли. КамАЗ төзелеше елларында Чаллы шәһәренә күчеп килеп, геодезист, төзүче һөнәрләрен үзләштерә, "КамАЗ төзелеше бәрмәчесе" исемен ала. «Якты юл» газетасында эшли башлагач, журналистка хас асыл сыйфатлары ачыла.

Аның әдәби мирасы артык мулдан түгел, шулай булса да, затлы иҗат ул. 1967 елда «Исәнмесез» дип аталган беренче җыентыгы дөнья күрә, 1981 елда «Алтын тояк», 1985 елда «Дөньяның матур җире» һәм балалар өчен «Чикерткә ник сикерә?» китаплары укучылар кулына барып ирешә.

Шагыйрь 1994 елның 7 октябрендә вафат була.

ТУКАЙ

Ул Пушкиннар нәселеннән иде
Уй белән дә, шигырь белән дә.
Шул нәселгә хас бер кодрәт иде
Ул тибрәткән очлы каләмдә.
Үзе инде гасыр башыннан ук
Кереп калган олы тарихка.
Тукай киткән...
Йөрәк әйтә сыман:
– Без Тукайсыз әллә калыйкмы?
Туган көнен бәйрәм итәр вакыт, –
Кайда йөри үзе юбиляр? –
Ул Казансыз минут яшәмәде,
Кайтыр әле, диләр күңелләр.
Кайтыр әле,
Әнә безгә дигән
Калын томы ята өстәлдә.
Без укыдык аны зур тормышка
Агач бишекләрдән күчкәндә.
Без укыдык, укый яңа буын,
Укыр аны туар кешеләр, –
Кешеләр бит Пушкиннары белән,
Тукайлары белән көчлеләр...
Туган көнен бәйрәм итәр вакыт,
Уйнат, әйдә, «Тукай маршы»н.
Ишетсен ул үзенең алгы сафта
Безнең белән атлап барышын.

РОССИЯ

Россия миңа шахтёр кебек тоела:
Озын буйлы, калын җилкәле.
Ул теләсә – таулар булып өелә
Җир өстенә күмер кибәне.
Россия миңа – корыч коючыдай,
Вулкан булып кайный корычы.
Корыч белән шулай нигез салып,
Ныгыта ул безнең тормышны.
Россия ул – әкияттәге егет,
Бәхет кошы тоткан кулына.
Һәм яктырта аны кояш сыман
Кешелекнең барыр юлында.

АВТОБИОГРАФИЯДӘН

Алтын түгел, бары агач бишек
Күткән минем дөнья күрүне.
Нурын чәчкән тырышып
бишле лампа,
Өйгә тулган фәкать сөреме.
Буялмаган такта иданнәргә
Салганмын мин тәүге эземне.
Тик шулай да төрле задәләрдән
Бәхетлерәк саныйм үземне.
Тормыш белән елап күрешсәм дә,
Ул елмаеп миңа караган.
Җан эреткеч йомшак куллар белән
Чәчләремне җиле тараган.
Мәктәпләре ачкан ишекләрен,
Көләч дуслар биргән иптәшкә.
Тормыш үзе шулай юмарт икән –
Күк күкрәтеп нигә үсмәскә!
Йөрим дисәң – җире теләгәнчә,
Йөзим дисәң – чиксез сулары.
Очыйм дисәң – сиңа һава ачык,
Үрлә, кеше, үрлә югары!..

АК КАЕННАР ЗАРЫ

Аккаеннар шаулый Россиямдә,
Яшьтәшләрен алар эзлиләр:
– Кырык бердә киткән яшь егетләр
Нигә безнең янга килмиләр.
Бергә үстек, бергә каршыладык
Сызылып аткан алсу таңнарны.
Сагындыра, сагындыра икән...
Безнең хәлне алар аңлармы?
Көнбатыштан каен шавы белән
Җил китерә яшьләр авазын:
– Җиргә кабат сугыш кертмәс өчен
Без әлегә монда калабыз.

АВЫЛЫМ УРАМНАРЫ

Илгиз ЗАКИРОВ көе

Таллары шаулый җилләрдә,
Көйли күрешү көен.
И минем туган авылым,
И минем туган өем.

Оныта алмыйм, онытмыйм
Авылым урамнарын –
Хәтер булып еракларга
Сузыла торганнарын.

Үз итеп яшәсәм дә мин
Илемнең башка ягын,
Авылымда көтеп тора
Күптәнге балачагым.

Оныта алмыйм, онытмыйм
Авылым урамнарын –
Хәтер булып еракларга
Сузыла торганнарын.

Рәхмәтемне белдерергә
Сүзләрем җитми минем.
Кырларың, урамнарың күк
Күңелең иркен синең.

Оныта алмыйм, онытмыйм
Авылым урамнарын –
Хәтер булып еракларга
Сузыла торганнарын.

СИНЕ ЯРАТКАНГА КҮРӘ

Фәрит ХАТЫЙПОВ көе

Елмаеп миңа карадың
Бу чынлап каравыңмы?
Белсәң иде сине күргән
Көннәрне санавымны...

Татлы уй өермәсендә
Еракларга очамын.
Сине яратканга күрә,
Бар дөньяны кочамын.

Мин сагынып сиңа барам
Син дә кил миңа каршы
Икебездә икән безнең
Олы мәхәббәт башы.

Татлы уй өермәсендә
Еракларга очамын.
Сине яратканга күрә,
Бар дөньяны кочамын.

Булмасын, урын калмасын
Күңел сүрәнлегенә
Икәү бергә керик әле
Сөю тирәнлегенә.

Татлы уй өермәсендә
Еракларга очамын.
Сине яратканга күрә,
Бар дөньяны кочамын.

Ләбиб ЛЕРОН

Хуш, иске ел!

(Гаилә президенты Әфләтун Бадрикаевнең Яңа ел котлавы)

Мөхтәрәм гаилә әгъзалары – газиз әнием, кадерле әтием, сөекле хатыным Индира, сөекле хатынымның кадерле әнисе Гөлмәрфуга, һәм дә ки, яраткан улым Арбитр белән киленем Агафья, кызларым Тереза белән Флорида, кияүләрем Амаяк белән Лиу Хи, оныкларым Эллари, Ашот, Кинг Шан!

Исәнмесез! Әссәламегаләйкем! Здравствуйте! Ни хао!

Кадерлеләрем, Яңа ел инде ишек шакый. Үткән елга йомгак ясар чак җитте. Гаилә президенты буларак, сезгә әйтәсе сүзләрем бар. Белгәнегезчә, узган ел башында мин, сезнең вазыйфаларыгызны кабаттан раслап, чираттагы указымны чыгарган идем. Хәзер шул указны яңартып-раслап тормыйча гына үз көчендә калдырам. Шул нисбәттән, вазыйфаларыгызны искә төшереп үтәм. Әти Эчке эшләр министры булып калачак. Ул, һәрвакыттагыча, гаиләдәге тәртип өчен җаваплы кеше. Эчке эшләр министрының тырышлыгы нәҗитәсендә, коррупция белән ришвәтчелек – безнең гаилә өчен ят күренеш. Хәтә, оныгым Ашот, фатирыбызның бер бүлмәсен шәхсән үзенеке итү өчен, атасыннан әллә айфонга, әллә айпатка, әллә смартфонга дип акча алып, финанс министрына, ягъни Индира әбисенә шуны төртергә маташкан. Ярый әле бу хәлне эчке эшләребезгә тыкшынучы министрыбыз, ягъни хөрмәтле Гөлмәрфуга Маратовна, вакытында күреп алып, бик тиз чарасын күргән. Форсаттан файдаланып, Гөлмәрфуга Маратовнаны Кызыл хач билгесе белән бүләкләргә рөхсәт итегез! Ашот улым, авызыңны турсайтырга ашыкма. Кем әйтмешли, тиздән синең урамга да бәйрәм килергә тора: Кинг Шан туганың тиздән әти-әнисе белән бергә Кытайга кайтып китәргә җыена. Лиу Хи кияү, КПРФ әгъзасы сыйфатында, туган илендә бер еллык командировкада булачак. Бездән үрнәк алып, анда да берсәк дөнья бутап алырга исәбе. Чү, сөенечеңнән ул кадәрле үк сикермә, Ашот улым, кытайский гамактан мәтәлеп төшүең бар!

Газиз гаиләм минем! Вазыйфаларыгызны искә төшерүемне дәвам итәм. Улым Арбитр – фатирыбызның мэры. Бик булдыклы. Эшен яратып башкара. Тышта зәмһәрир кыш булуына карамастан, бу араларда өйдә гөл утырту эшен җанландырып җибәрде. Күрегез, хәзер кая карама – шунда яшеллек.

Тик бераз тәнкыйть сүзләре әйтмичә булмый үзенә. Игътибар иткәнсездер, фатир буйлап йөрүләр кыенлашты. Бер бүлмәдән икенчесенә тиз генә барып җитеп булмый. Бөтен җирдә – кухняда, залда, ванна, сауна һәм туалет бүлмәсендә, балконда капиталь ремонт бара. Ремонт 31 декабрьгә төгәлләнергә тиеш иде. Эшнең әле очы-кырые күренми. Туалет, дигәннән... Көн саен иртә белән аңа барасы юлда "бөке" хасил була. Мэр әйтә, туалетка баруны түләүле итәргә кирәк, ди. Шул чакта гына "бөке"дән котылачакбыз, ди. Ай-һай, котылырбыз микән? Мин шәхсән моңа шикләнеп карыйм. Ярты елдан тагын зур бәйрәм – Сабантуй җитә. Аңарчы, бер-ике өмә оештырып, фатирны рәткә китерергә кирәк. Инде килик социаль яклау министры вазыйфасын алып баручыга. Бу эшне әни (минем өчен – әни, сезнең күбегезгә – әби) бик теләп һәм яратып башкара. Аңа рәхмәттән башка сүзем юк. Кызым Тереза – фатир советы депутаты, минем ышанычлы киңәшчем. Амаяк кияү – Әрмәнстанның безнең гаиләдәге вәкаләтле илчесе. Безнең гаилә белән Әрмәнстан арасында менә ничә еллар инде ныклы элемтә һәм дустанә мөнәсәбәт яшәп килә. Монда, әлбәттә, Амаяк кияүнең өлеше әйтеп бетергесез. Флорида кызым безнең гаиләдә, Кытай халкы санын арттырып, үзеннән зур өлеш кертергә җыена. Ул шулай ук минем тугрылыклы киңәшчем, Кытай буенча зур белгеч, Лиу Хи кияү белән безнең арада менә дигән тәрҗемәче. Барысын да алдан хәстәрен күреп эш иткәндә, аның эшчәнлеге бүгенге көндә бик мөһим.

Лиу Хи кияүгә килсәк, ул – эшмәкәр. Фатирыбыздагы ике бүлмә Кытайда эшләнгән ширпотреблар белән шыгрым тулы. Эшләр болай барса, тиздән кытай-вьетнам базары тулаем безнең фатирга күчмәгәе. Ары китеп, бире килдек. Киленем Агафьяның вазыйфасы – бик җаваплы, бик җитди. Ул фатирыбыз мэры Арбитр Әфләтуновичның керемнәрен һәрдаим күз уңында һәм үзендә тотучы уңган хуҗабикә. Мэриянең финанс балансын нульгә кадәр төшереп, еш кына фатир халкын телсез-өнсез калдырырга ярата. Афәрин, Агафья! Шул кирәк безгә!

Быел зур эшләр башкардык. Тел мәсьәләсендә бераз проблема булып алды, анысы, әйе. Быел да яраткан телебезне үзебезнең табынга хәстәрләп куя алмадык. Агафьяның теләге үтәлде: бу юлы да керәшен сарыгы теле белән канәгать булып калдык. Кыскасы, син дә, мин дә – тел остасы дигәндәй... Йомгаклап шуны әйтәм: без исән, без бар, без булдырабыз, о кей!

Барыгызны да Яңа ел бәйрәме белән котлыйм! Игътибар белән тыңлаганыгыз өчен рәхмәт! Спасибо! Шноракалутюн! Сесе! Фэй чһан ган се!

Сүзлек:
Барэв дзес – исәнмесез (әрмәнчә).
Ни хао – исәнмесез (кытайча).
Шноракалутюн – рәхмәт (әрмәнчә).
Сесе – рәхмәт (кытайча).
Фэй чһан ган се – зур рәхмәт (кытайча).




ЧАЯН
САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 2 (1951) февраль 2025

Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылა алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.02.2025 ел.
Тираж – 1470 Заказ М-0105
Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. "Бесприданница" пьесасы белән Роскомнадзорның Youtubeның кыйметү мәсьәләсендә нинди уртаклык бар?

2. Аңгыралык килеше нинди сорауларга җавап бирә?

3. Кемнәр алар бирсәярләр?

4. Диетада төп нәрсә?

5. Ялган белән дөреслек арасында нинди аерма?

6. Соры төркемнән аерылып тору өчен нишләргә кирәк?

7. Ксения Собчак үзенең буш вакытын ничек үткәрә?

ҖАВАПЛАР

1. Син беркемгә дә калма! 2. Нәрсә? 3. Никадәр генә тырышсалар да, үз хатыннарыннан башка яхшырак бирәүне дә таба алмыйлар. 4. Йокы. Вакытында йоклап китмәсәң – туенгансың. 5. Ялганда һәрвакыт шаһитлар бар, ә дөреслектә беркайчан да юк. 6. Дөрес языгыз. 7. Гадәттәгечә – Европа буйлап сикертеп чабып.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 1 нче санында басылган чаянвордныңтикшерү сүзе – **«КАРШЫ АЛ, ТУГАН КАЛАМ!»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Р. НУРГАЛИЕВ (Бөгелмә),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан).

Җиңүчебез – Чаллыдан


Гали БАҺАВЕТДИНОВ!


Алексей МАМАЕВ



Алексей Мамаев рәссам-бутафор белгечлеге буенча Казан театр училищесын тәмамлаган, ләкин рәссам-карикатурачы буларак танылა. Кем әйтмешли, тормыш – театр. Һәм ул драматурглар каләменә тиң сюжетлар тудыра. Алексей «Чаян»да дистә елдан артык нәшер итә һәм бүген ул укучыларга көндәлек тормышыбызның берничә күренешен тәкъдим итә. Талантлы рәссамның тагын бер рәсеме бу санның тышлыгын бизәп тора.






4612750670080